**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 февраль № 90

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы (элекке Тукай урамы), 97 нче йорт адресы буенча урнашкан «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен һәм аннан файдалану режимын раслау турында» 2013 ел, 17 гыйнвар, 15 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы (элекке Тукай урамы), 97 нче йорт адресы буенча урнашкан «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен һәм аннан файдалану режимын раслау турында» 2013 ел, 17 гыйнвар, 15 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә, 1 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда «(элекке Тукай урамы), 97 нче йорт» сүзләрен «, 97 нче йорт (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт)» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы (элекке Тукай урамы), 97 нче йорт адресы буенча урнашкан «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен һәм Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы (элекке Тукай урамы), 97 нче йорт адресы буенча урнашкан «Петцольдның сыра кайнату

заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын тиешенчә бу карарга теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталар редакциясендә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\90.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 16 февраль, 90 нчы
карарына 1 нче кушымта

**Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 97 нче йорт адресы буенча урнашкан (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт) «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре**

Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 97 нче йорт адресы буенча урнашкан (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт) «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картасы (схемасы)**




**Шартлы билгеләр:**

– мәдәни мирас объекты территориясе
– мәдәни мирас объекты
– гамәлдәге биналар һәм корылмалар

Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 97 нче йорт адресы буенча урнашкан (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт) «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 97 нче йорт адресы буенча урнашкан (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт) «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

көньяк-көнбатыш өлеше: 1 нче ноктадан (булган 97 нче А йорт почмагы) булган биналар буеннан Габдулла Тукай урамы буйлап төньяк-көнбатышка таба кызыл линия буенча 2 нче ноктага кадәр, 1 нче ноктадан 2 нче ноктага кадәр ара – 150,0 метр;

төньяк-көнбатыш өлеше: 2 нче ноктадан булган бина кырыеннан 3 метр ераклыкта Шиһабетдин Мәрҗани урамына таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә 3 нче ноктага кадәр. 2 нче ноктадан 3 нче ноктага кадәр ара – 67,3 метр. 3 нче ноктадан көньяк-көнчыгышка таба булган бина стенасы буендагы 4 нче ноктага кадәр. 3 нче ноктадан 4 нче ноктага кадәр ара – 22,5 метр. 4 нче ноктадан төньяк-көнчыгыш юнәлештә Шиһабетдин Мәрҗани урамына таба коймага кадәр. 4 нче ноктадан 5 нче ноктага кадәр ара – 26,5 метр;

төньяк-көнчыгыш өлеше: 5 нче ноктадан Шиһабетдин Мәрҗани урамы буйлап койма буеннан көньяк-көнчыгышка таба 6 нчы ноктага кадәр. 5 нче ноктадан 6 нчы ноктага кадәр ара – 27,5 метр. 6 нчы ноктадан көньяк-көнчыгыш юнәлештә Габдулла Тукай урамына таба булган бина буеннан 3,0 метр ераклыкта 7 нче ноктага кадәр. 6 нчы ноктадан 7 нче ноктага кадәр ара – 54,0 метр. 7 нче ноктадан Габдулла Тукай урамы буйлап көньяк-көнчыгышка таба кызыл линиягә параллель рәвештә 8 нче ноктага кадәр. 7 нче ноктадан 8 нче ноктаган кадәр ара – 42,0 метр. 8 нче ноктадан төньяк-көнчыгыш юнәлештә Шиһабетдин Мәрҗани урамына таба арыш, арпа оны кайнату бинасы буеннан 5,0 метр ераклыкта 9 нчы ноктага кадәр. 8 нче ноктадан 9 нчы ноктага кадәр ара – 62,5 метр. 9 нчы ноктадан көньяк-көнчыгышка таба Шиһабетдин Мәрҗани урамындагы койма буйлап 10 нчы ноктага кадәр. 9 нчы ноктадан 10 нчы ноктага кадәр ара – 40,5 метр;

көньяк-көнчыгыш өлеше: 10 нчы ноктадан көньяк-көнбатыш юнәлештә Габдулла Тукай урамы ягына таба булган өч катлы арыш, арпа оны кайнату бинасыннан 4,5 метр һәм бер катлы бинадан 8,0 метр ераклыкта урнашкан 11 нче ноктага кадәр. 10 нчы ноктадан 11 нче ноктага кадәр ара – 23,5 метр. 11 нче ноктадан көньяк-көнчыгышка таба өч катлы арыш, арпа оны кайнату бинасыннан 12,0 метр һәм ике катлы бинадан 28,75 метр ераклыкта урнашкан 12 нче ноктага кадәр. 11 нче ноктадан 12 ноктага кадәр ара – 7,5 метр. 12 нче ноктадан көньяк-көнбатыш юнәлештә Габдулла Тукай урамына таба, бер катлы бинадан 3,75 метр

һәм ике катлы бинадан 4,75 метр ераклыкта урнашкан 13 нче ноктага кадәр. 12 нче ноктадан 13 нче ноктага кадәр ара – 24,0 метр. 13 нче ноктадан көньяк-көнчыгышка таба ике катлы бинадан 6,75 метр ераклыкта. 13 нче ноктадан 14 нче ноктага кадәр ара – 17,0 метр. 14 нче ноктадан көньяк-көнбатыш юнәлештә Габдулла Тукай урамына таба ике катлы бинадан 3,5 метр ераклыкта, 97 нче А йорттан 4,5 метр ераклыкта урашкан 15 нче ноктага кадәр. 14 нче ноктадан 15 нче ноктага кадәр ара – 22,5 метр. 15 нче ноктадан 97 нче А йорт стенасына кадәр төньяк-көнбатышка таба 16 нчы ноктага кадәр. 15 нче ноктадан 16 нчы ноктага кадәр ара – 4,5 метр. 16 нчы ноктадан 97 нче А йорт стенасы буйлап көньяк-көнбатышка таба 1 нче ноктага кадәр. 16 нчы ноктадан 1 нче ноктага кадәр ара – 20,0 метр.

Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 97 нче йорт адресы буенча урнашкан (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт) «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Ноктаның тәртип саны | Ноктаның координатлар җирле системасындагы (МСК-16) координатлары | | Ноктаның 1984 елгы координатларның бөтендөнья геодезия системасындагы (WGS-84) координатлары | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | төньяк киңлек | көнчыгыш озынлык |
| 1 | 473809.93 | 1305641.14 | 55° 46′ 17.92″ | 49° 07′ 17.67″ |
| 2 | 473941.91 | 1305570.30 | 55° 46′ 22.19″ | 49° 07′ 13.62″ |
| 3 | 473973.66 | 1305629.11 | 55° 46′ 23.21″ | 49° 07′ 16.99″ |
| 4 | 473953.81 | 1305639.85 | 55° 46′ 22.57″ | 49° 07′ 17.61″ |
| 5 | 473967.16 | 1305662.17 | 55° 46′ 23.00″ | 49° 07′ 18.89″ |
| 6 | 473943.18 | 1305675.06 | 55° 46′ 22.23″ | 49° 07′ 19.62″ |
| 7 | 473916.26 | 1305628.09 | 55° 46′21.36″ | 49° 07′ 16.93″ |
| 8 | 473880.08 | 1305647.83 | 55° 46′20.19″ | 49° 07′ 18.06″ |
| 9 | 473906.31 | 1305693.72 | 55° 46′ 21.03″ | 49° 07′ 20.69″ |
| 10 | 473870.91 | 1305712.39 | 55° 46′ 19.89″ | 49° 07′ 21.76″ |
| 11 | 473859.24 | 1305691.67 | 55° 46′ 19.51″ | 49° 07′ 20.57″ |
| 12 | 473852.19 | 1305693.81 | 55° 46′ 19.28″ | 49° 07′ 20.69″ |
| 13 | 473840.47 | 1305672.75 | 55° 46′ 18.91″ | 49° 07′ 19.48″ |
| 14 | 473825.80 | 1305681.85 | 55° 46′ 18.43″ | 49° 07′ 20.01″ |
| 15 | 473814.90 | 1305661.92 | 55° 46′ 18.08″ | 49° 07′ 18.86″ |
| 16 | 473818.97 | 1305659.62 | 55° 46′ 18.21″ | 49° 07′ 18.73″ |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 16 февраль, 90 нчы
карарына 2 нче кушымта

**Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 97 нче йорт адресы буенча урнашкан (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт) «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимы**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 17 гыйнвар, 15 нче карары белән расланган Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 97 нче йорт адресы буенча урнашкан (адресы ТАССР Министрлар Советының әлеге объектны дәүләт саклавына кую турындагы 1987 ел, 27 июль, 320 нче карары нигезендә - Казан шәһәре, Тукай урамы, 97 нче йорт) «Петцольдның сыра кайнату заводы комплексы, 1905 ел» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

мәдәни мирас объектын ремонтлау, консервацияләү һәм реставрацияләү;

мәдәни мирас объектының бөтенлеген бозмый һәм аның бозылу, җимерелү яки юкка чыгу куркынычын тудырмый торган хуҗалык эшчәнлеге;

саклау предметын тәшкил итүче үзенчәлекләрен үзгәртмичә функциональ файдаланырга рөхсәт ителгән төрләре нигезендә мәдәни мирас объектын заманча файдалану өчен яраклаштыру;

мемориал һәм архитектура ансамбле буларак әһәмияткә ия булган югалган тарихи элементларын фәнни нигездә элекке хәленә кайтару - регенерацияләү;

диссонанслы объектларны һәм вакытлыча корылмаларны бетерү;

ядкәр территориясендә урнашкан, тарихи-шәһәр төзелеше, архитектура-киңлек ягыннан һәм мемориал буларак зур әһәмияткә ия булмаган биналарның кыйммәтле элементларын консервацияләп һәм фасадларын реставрацияләп, мөмкин булганча техник модернизацияләп реконструкцияләү;

булган объектларның инженерлык инфраструктурасын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон кертү буенча тышкы челтәрләрне) капиталь ремонтлау;

төзекләндерү – мәйданчыкларны, якын килү һәм транспорт узу урыннарын каплауда традицион материаллардан (таштан, граниттан һәм табигый булып күренә торган башка материаллардан) файдалану;

тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирүче аерым тора торган яктырту җиһазларыннан файдалану, фонтаннар кую, яшелләндерү: агачларның кыйммәтле төрләрен саклау, парклар, аллеялар, газоннар, чәчәкләр утырту урыннарын ясау;

мәдәни мирас объектының беренче катыннан югары булмаган биеклектә мәдәни мирас объектлары фасадында мәгълүмати язулар һәм билгеләр, мемориаль такталар кую;

оешмаларның элмә такталарын, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 ел, 7 февраль, 2300-1 нче Россия Федерациясе Законы нигезендә эшләүченең (башкаручының, сатучының) атамасы, аның барлыкка килү урыны (адресы) һәм эш режимы турында кулланучылар игътибарына мәгълүмат җиткерү өчен билгеләнгән элмә язуларны һәм реклама конструкцияләрен бинаның, төзелмәнең яки корылманың беренче катыннан да югарырак булмаган биеклектә кую.

Югарыда билгеләнгән мәгълүмат конструкцияләренең биеклеге чикләрендә теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлана торган катларның тәрәзәләре арасындагы аралык, фриз биеклегенең 2/3 өлешеннән артмаска тиеш, моңа декоратив-сәнгать паннолары керми. Аркалы тәрәзәләр булганда катлар арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге 1/2 гә кадәр кими.

Мәгълүмат конструкцияләренең киңлеге, чикләрендә теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлана торган аралык киңлегенең 2/3 нән артмаска тиеш, моңа декоратив-сәнгать паннолары керми.

Югарыда күрсәтелгән барлык эшләр Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән килештерелергә тиеш.

Җир кишәрлегеннән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре: мәдәният объектлары, җәмәгать тукलануы, күңел ачу, кунакханә хезмәте күрсәтү, сәүдә үзәкләре, спорт объектлары, эшлекле идарә итү, көнкүреш һәм социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, белем бирү һәм мәгърифәт, иҗтимагый идарә, фәнни эшчәнлек, кибетләр, банк һәм иминият эшчәнлеге, йөреп кайтулар, табигать-танып-белү туризмы.

Күрсәтелгән төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр тыела:

капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен урнаштыру, шулай ук җир төзелеше эшләрен, җир, төзелеш, хуҗалык эшләрен һәм мәдәни мирас объектын саклауга бәйле булмаган башка эшләрне проектлау, үткәрү;

мәдәни мирас объекты фасадында һәм түбәсендә кондиционерлар, эре габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын кую;

җир өсте ысулы белән инженерлык инфраструктурасы объектларын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон кертү буенча тышкы челтәрләр) үткәрү;

киосклар, павильоннар, өслекләр кую, югалганнарын торгызудан тыш;

агачның кыйммәтле төрләрен кисү, санитария максатында кисүдән башка;

парковкалар төзү.

---